ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“15” ноябрь 2021 ел                                                                                    № 14

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең Шилнәбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Шилнәбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 26 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта Шилнәбаш авылында Нагорный, Төньяк, яңа, Заречная урамнары буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2021 елның 26 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Шилнәбаш авылында мәктәп, Октябрьнең 60 еллыгы, буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2021 елның 26 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта Шилнәбаш авылында Мордвинов, Яшьләр, Кыр,Октябрьнең 60 еллыгы, белгечләр тыкрыгы буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Шилнәбаш авыл җирлегенең Шилнәбаш авылы территориясендә 2022 елда балигъ булган, Шилнәбаш авыл җирлегенең Шилнәбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- тротуар, җәяүлеләр өчен күперчек һәм парковка төзү эшләрен башкару;
-гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү ("Безнең ишегалды" программасында катнашу өчен сарайларны сүтү һәм утильләштерү);
- юлларга вак таш җәю, чокырларны ямау;
- Октябрьнең 60 еллыгы урамында су башнясын реконструкцияләү ;

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ”                                        “ЮК”.

5. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Шилнәбаш авылы, Октябрьнең 60 еллыгы ур., 2 йорт.

Шилнәбаш авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.

6. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

8. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Шилнәбаш авыл
җирлеге Башлыгы — О.А. Гончарова

Исполнительный комитет ШИЛЬНЕБАШСКОГО сельского поселения